ГЛАВА ВАХИТОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ ВАХИТОВ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Бакча Сарай поселогында 2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2025 елның 22 ноябреннән №3

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45,69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Бакча Сарай поселогында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегенең Бакча Сарай поселогында яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, 1 төркем инвалидлар; СВО зонасына мобилизацияләнгәннәр һәм аларның гаилә әгъзалары (РФ Гаилә кодексының 2 ст. нигезендә), РФ Оборона министрлыгы, шулай ук башка ведомстволар (Росгвардия, ЧВК, РЖД һ.б.) белән контракт төзегәннәр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш (РФ Гаилә кодексының 2 ст.нигезендә) 2026 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә. Түләүләр күләме түбәндәге категория гражданнар өчен гражданнар җыены карарында билгеләнгән сумманың 50 процентын тәшкил итә: күпбалалы гаиләләр; көндезге уку йортлары студентлары; чакырылыш буенча вакытлы хәрби хезмәт узучы хәрби хезмәткәрләр; тыл хезмәтчәннәре.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- торак пункт территориясен төзекләндерү

3. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, Вахитов авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Җыелышта рәислек итүче Ф.Р. Каримов